**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**2024елның 7 марты** **13-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2024 елның 30 гыйнварындагы 10-53/1013 номерлы Хәерби авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен карап, 2024 елның 15 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022елның 07 сентябрендәге 64-РС номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022елның 18 маендагы 37-РС номерлы карары кертелгән үзгәрешләре белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең генераль планына (1 нче кушымта) үзгәрешләр кертү проектын расларга.

2. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**